КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 19

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 19 апрель, 315 нче карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 19 апрель, 315 нче карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «2014 – 2021» саннарын «2014-2025» саннарына алмаштырырга;

4 пунктта «(алга таба – Казначылык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «Казначылык» сүзен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның өченче абзацында «проектлау яки төзү буенча» сүзләрен «проектлау һәм (яки) төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация, техник яктан яңадан коралландыру элементлары белән)» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның өченче абзацында «проектлау яисә төзү буенча» сүзләрен «проектлау һәм (яки) төзү (реконструкцияләү (шул исәптән реставрация, техник яктан яңадан коралландыру элементлары белән)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар аңа имза куйган көннән үз көченә керә;

әлеге карарның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларының гамәлдә булуы 2019 елның 11 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин